# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче Красная Горка авылында 2022 елга үзара салым кертү турында

№ 14

18.11. 2021 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Красная Горка авылында узган гражданнар җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Красная Горка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2022 елда 400(дүрт йөз) сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелганак чаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
-Красная Горка авылында юлларны тозекләндерү (сатып алу, күчереп йөртү, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
-Красная Горка авылында су белән тәэмин итү линиясен ремонтлау;
-Красная Горка авылында тукталыш павильоны сатып алу һәм урнаштыру;
-Красная Горка авылында каты көнкүреш калдыклары контейнеры өчен мәйданчыклар төзү;
-Кызыл Тау авылында янгын сүндерү гидранты һәм аңа корылма сатып алу һәм урнаштыру;
-Красная Горка авылы урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү;
-Красная Горка авылында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру).

3.Әлеге карарны Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе

В.А. Гиззатуллина